ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

23.12.2022 г.Мензелинск № 431

Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Минзәлә муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакын күтәрү турында»23.11.2012 ел № 1347 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт өчен түләү Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын күтәрү турында» 14.06.2011 ел № 477 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 1 нче кушымтасына үзгәреш кертү хакында " 2022 ел, 13 декабрь №987 карары нигезендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Минзәлә муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакын күтәрү турында» 23.11.2012 ел № 1347 карарына (Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 24.10.2013 ел № 1071 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 19.03.2014 ел № 265, 12.12.2014 ел № 1264, 23.11.2015 ел № 816, 14.07.2016 ел № 776, 24.08.2017 ел № 807, 02.02.2018 ел № 98, 18.02.2022 ел  № 49) түбәндәге үзгәрешләр:

күрсәтелгән карарга № 1 кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (беркетелә).

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ рәисе Л.И. Кондратьевага йөкләргә.

Җитәкче М. Р. Кәримов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесенең карарына
23.11.2012 ел №1347

23.12.2022 № 431

# МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БЮДЖЕТЫННАН ФИНАНСЛАНА ТОРГАН БЮДЖЕТ ӨЛКӘСЕ ТАРИФ КОЭФФИЦИЕНТЛАРЫ ҺӘМ ТАРИФ СТАВКАЛАРЫ (ОКЛАДЛАР) ХЕЗМӘТКӘРЛӘР ХЕЗМӘТЕНӘ ТҮЛӘҮ БУЕНЧА БЕРДӘМ ТАРИФ ЧЕЛТӘРЕ

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,00 | 15 279 |
| 2 | 1,0159 | 15 522 |
| 3 | 1,0323 | 15 773 |
| 4 | 1,0480 | 16 012 |
| 5 | 1,0656 | 16 281 |
| 6 | 1,0827 | 16 543 |
| 7 | 1,1010 | 16 822 |
| 8 | 1,1187 | 17 093 |
| 9 | 1,1363 | 17 362 |
| 10 | 1,1553 | 17 652 |
| 11 | 1,1736 | 17 931 |
| 12 | 1,1933 | 18 232 |
| 13 | 1,2129 | 18 532 |
| 14 | 1,2325 | 18 831 |
| 15 | 1,2528 | 19 142 |
| 16 | 1,2738 | 19 462 |
| 17 | 1,2947 | 19 782 |
| 18 | 1,3163 | 20 112 |

Искәрмә. Җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 - 2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.